

Фатих Асыйм улы белән Рушания Рафик кызы Азисовлар ике малай һәм бер кыз бала тәрбияләп vстерәләр. Үзләре бар яктан да тырыш, булдыклы, тәрбияле булганга, балаларына да kvз тимәсен; берсе-берсеннән артык. Әйе, бер дә арттырмыйм. Ике лачын улы тормышта vз урыннарын табып олы юлга чыкканнар, ә топчек кызлары Азалия – Саранск шәһәренен 17 мәктәбенен сигезенче сыйныфында бик тә тырышып укый. Әнисе тосле, жәмгыяви эшләрдә бик тә актив, конкурс белән олимпиадаларда да катнаша. Катнашып кына калмый, унышларга ирешә. Менә шулай анын бер конкурс эше – «Әбием пәрәмәчләре» эссесын тәгъдим итәбез. …Карангы кич, яна гына пешерелгән тәм-томнар исе ой буена тарала. Ә әнием белән әбием аш-су белән мәшгуль; алар татар халкынын милли бәйрәмебезгә әйләнгән бәйрәмгә – Корбан бәйрәменә әзерләнә. Әзерлек озын-озакка сузылырга момкин, әмма бу һәрвакыт шатлык, чонки иртәгә кунаклар жыела: безнен әби-бабайларыбыз, барлык туганнар һәм якын дуслар киләчәк. Традицияләр шундый, тәртип шундый. Kvпләрнен татар мәдәнияты белән танышу нәкъ менә милли ашлардан башлана да инде. Кыстыбый, гобәдия, чәк-чәк, очпочмак, баурсак ... хәтта исемнәре дә матур. Алар, әйтерсен, әниләрнен жылы куллары белән жылытылган кебек. Татар ашлары белән туристлар яки даими яшәvчеләр таныш, анын тәмле һәм туклыклы булуын, ингредиентларнын гадиләре кулланылса да, аш-су бик тиз табыннан бетәчәген барысы да белә. Ә хужалар һәрвакыт кунакчыл һәм ярдәмчел. Борынгы татар гадәте буенча, кунак хормәтенә бәйрәм ашъяулыгы жәелә һәм табынга ин яхшы ризыклар – баллы чәк-чәк, бавырсак, кош теле, ширбәт, юкә балы һәм, әлбәттә, хуш исле чәй куела. Борын-борыннан татар мәдәниятындагы кунакчыллык һәрвакыт югары бәяләнде. «Кунакчыллык kvрсәтмәгән кеше – гарип», – дип санаганнар. Кунакларны сыйлап кына калмыйча, бvләкләр дә биреп жибәрәләр. Гадәт буенча, кунак та шуна жавап итеп бvләк бирә. Халыкта: «Кунак ашы - кара каршы», - дип юкка гына әйтмиләр. Табадан кайнар майны йотып, бәлеш кызарып беткән, һәм мин vземнен kvп кенә буын хатын-кызларымнын бәйрәмгә шулай әзерләнvләрен, традицияләрне дәвам итәчәкмен, ә аннары балаларымны да шуна ойрәтәчәкмен. Юкка тvгел, минем ин матур истәлекләремнен берсе булып әбием белән бәйрәмгә әзерләнvем бvген дә якты хәтер булып тора. Кечкенә чагым, остәлдән тvбәм генә kvренеп тора. Барысы да бәйрәмгә әзерлек белән мәшгуль. Минем дә әзерләнvдә катнашасым килә. Әбием камыр изгән, олергән камырны кечкенә шарчыкларга бvлеп бара. Кул астында буталганга kvрә, мина да кечкенә шарлар ясарга ышандылар. Шул вакыт мин бик тә тырышуым хәтердә; тирләп-пешеп эшлим шул шарчыкларны, ә әбием татар ашлары турында сойли. Ул һәр

милли ризыкнын vз тарихы һәм эчтәлеге бар дип сойләде. Мәсәлән, кызлар кvмәче - танылган чәк-чәк, кәләш ризыгы булуын әйткәне хәтеремдә. Элек, традиция буенча, татар туйларында аны кәләш vзе тырышып әзерли торган булган. Ул, якты кояш тосле, якты сары тостә, ә балга сыланган шарлар халкыбызнын никадәр бердәм һәм тату булуын кvрсәтә. Донья инде кvптәннән vзгәрде һәм кызларга бәхетле булу очен ин яхшы кулинар булырга кирәкми дә, әмма бу традицияләргә хормәт буларак буыннар бәйләнешен, чорлар бәйләнешен саклау һәм якыннарыбызны соендерер очен кирәк. Белгәнебезчә, милли татар ашлары-бызнын барлыкка килvе кvп факторларга бәйле. Торекләрдән катык, бал-май, кабартма алдык, руслардан – пилмән, кытайлылардан - чәй, vзбәкләрдән - плов, халва, ширбәт, ә тажиклардан – пәхләвәне алдык. Милли аш-су әзерләv тәжрибәбез рус милләтлеләр кухнясына дә йогынты ясады, мәсәлән, рус пешекчеләре продуктларны кыздыру технологиясен татарлардан алганнар.
Татарларда чәй белән кызыклы вакыйга булган. Традицион милли эчемлегебез булмаса да, ул мәдәниятыбызга нык кереп калган, хәзер хәтта татар чәенен аерым рецептлары да бар. Чәебезгә һәрвакыт татарлар яшәгән жирлектәге vлəннәр остәлгән: бетнек, мәтрушка, юкә чәчәге, голжимеш, кvрәгә һәм бу эчемлеккә тагын кvп нәрсә остиләр. Терелтә торган чәем, дип юкка гына хужабикәләр әйтмидер. Чәйнен куелыгы хужанын юмартлыгын да, жирле традицияләрне һәм vзенчәлекләрне сендергән халык рухынын ныклыгын да гәvдәләндерә. Шул регион болыннарында vскән чәчәкләр бәйләме кvк, татарлар чәйләрен мул һәм vзенчәлекле иттереп ясыйлар.
Халыкнын тагын бер моһим милли традициясен әйтми булдыра алмыйм. Ул – кичке аш (званый ужин). Татарлар аны тантаналы һәм кайгылы вакыйгаларга – балага исем кушуга (имянаречение), никахка (мусульманская свадьба), «кул кvтәрv» дип аталган ой туена (новоселье) әзерлиләр. «Аш»ларыбыз кызыклы уза. Барысы да остәл артында утырыша: ашыйлар, сойләшәләр, колә яки монсуланалар... Хәзер аралашу очен момкинлекләр кvп, әмма хормәтле туганнарыбыз, бай тормыш тәжрибәсе туплаган ыру-кардәшләребез белән кvзгә-кvз карашып аралашуны бернәрсә алмаштыра алмый. Халык: «Бер утырып сойләшvләр vзе бер гомер», - дип юкка гына әйтми. Ойдә vткәрелгән Кичке аш туганлык элемтәләрен ныгытырга, алдагы буыннар тәжрибәсен vзләштерергә ярдәм итә, бер гаиләнен берничә буын белән бергә аралашу момкинлеген бирә һәм татарлар әйткәнчә, - йортка рәхәтлек китерә.
Татар халкынын аш-суы – ата-бабаларыбызнын яшәv мирасы. Азык-толек кешеләр тормышынын ин моһим олешен тәшкил итә, ә азык кабул итv белән бәйле гореф-гадәт-ләр мәдәниятнен моһим олешенә әверелде. Эссе темам, бер карашка, гади дип тә кvренәдер, әмма минемчә - тирән мәгънәгә ия. Әйткәнемчә, татар халкынын милли ашлары – кояш кебек яна, кайнар, майлы ризыклар аша халкыбызнын ин якты, яхшы сыйфатларын ачып бирә. Бәйрәм ашлары, татлы ризыклар, тәм-томнар шатлык бvләк итә һәм «без сина шат», «сине ойдә котәләр, сине сагыналар», диләр кебек. Татар хатын – кызларыбыз аш-су әзерләгәндә дога кылырга һәм яхшы гына уйлар уйларга кирәк дигән кагыйдәне истән чыгармый һәм шул чакта ризык файдага бара һәм сәламәтлекне арттыра». Тагы, гаилә остәлендәге ризыклар ин тәмле һәм туклыклы булсын очен тырышкан хатын-кызга, барысы да ин зур «рәхмәт», - диләр. Бу безгә кан белән сенеп килгән гадәт. Әйе, без һәрвакыт vзгәрә торган доньяда яшибез. Әйберләр даими vзгәреп тора, мода vзгәрә, кешеләр vзләре vзгәрә. Безнен донья әби-бабайларыбыз доньясына бер дә охшамаган. Әйткәнемчә, без vзебез дә башкалар. Әмма, кvп гасырлар дәвамында vзгәрешсез кала торган ниндидер әйберләр бар...

Минемчә - халык традицияләре, мәдәни кыйммәтләр, Россия байлыгы һәм тарихы үзгәрешсез калачак. Һәр кешенен мәдәни кыйм-мәтләрне анлауга үз юлы бар һәм шул юлдан бара. Минем дә әбием пәрәмәчәлеләре үз юлым бар һәм минем бу юлдан лаеклы үтәсе килә...

Азалия Азисова